**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноября 2022г. с. Тюлячи № 255

2023, 2024, 2025 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 27 декабрендәге 1220 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 3 сентябрендәге 957 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыскасроклы планына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023, 2024, 2025 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«22» 11 2022 № 255
карарына кушымта

**2023, 2024, 2025 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның әлеге Кыскасроклы планы Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырыла торган төрләрен төгәлләштерү, дәүләт ярдәме төрләрен һәм муниципаль ремонт үткәрүнең күләмен билгеләү максатларында эшләнелде.

## II. Кыскасроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыскасроклы планның төп максатлары булып тора:

Теләче муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

- гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру; күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм күрсәтү.

Кыскасроклы планның төп бурычлары булып тора:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

Кыскасроклы планны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле һәм ачык процедураларын эшләү һәм үтәү;

озак вакытлы материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләре кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны куллану.

Кыскасроклы планны гамәлгә ашыру срогы - 2023, 2024, 2025 еллар.

Кыскасроклы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 2 мең кв. метр булган 3 күпфатирлы йортта 42 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш. Әлеге Кыскасроклы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр Кыскасроклы планга карата 1 номерлы кушымтада күрсәтелгән.

## III. Кыскасроклы планны үтәүдә катнашучы авыл җирлекләре исемлеге

Кыскасроклы планны үтәүдә катнашучы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре исемлеге мондый җирлекләрнең территориясендә түбәндәгеләрнең булуын исәпкә алып формалаштырылды:

а) Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгән;

б) Теләче муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә планны гамәлгә ашыруның муниципаль Кыскасроклы (еллык) планнары дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән расланды һәм килештерелде.

Кыскасроклы планны тормышка ашыруда Теләче авыл җирлеге катнаша.

## IV. Күп фатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме

Күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре түбәндәге адрес буенча:
ТР, Теләче районы, Теләче ав., Кооперативная ур., 7а й.
2023 елда

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Фасадны ремонтлау һәм җылыту | кв. метр | 780 |

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме:
ТР, Теләче районы, Теләче ав., Кооперативная ур., 7а й.
2023 елда

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү системасын ремонтлау | метр | 320 |

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме:
ТР, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 68а й.
2023 елда

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | кв. метр | 80 |
| Йорт эчендәге инж. салкын су бирү системаларын ремонтлау | кв. метр | 85 |

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме:
ТР, Теләче районы, Шармаш ав., Школьная ур., 60 й.
2024 елда

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Фасадны ремонтлау | метр | 165 |

| | | |
|---|---|---|
| Түбә ремонтлау | кв. метр | 383 |
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | пог. метр | 30 |
| Йорт эчендәге инж. системасын ремонтлау | пог. метр | 30 |

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме:
ТР, Теләче районы, Теләче ав., Дальняя ур., 1а й.
2025 елда

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | пог. метр | 30 |
| Йорт эчендәге инж. системасын ремонтлау | пог. метр | 30 |

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме:
ТР, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 68а й.
2025 елда

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Электр белән тәэмин итү системасын ремонтлау | пог. метр | 165 |
| Түбә ремонтлау | кв. метр | 303 |
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | пог. метр | 79,7 |
| Йорт эчендәге инж. системасын ремонтлау | пог. метр | 85 |

Күп фатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләме Кыскасроклы планга 2 номерлы кушымтада «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган 2023, 2024, 2025 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры» китерелгән.

## V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыскасроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, жирле бюджетлар һәм күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре акчалары тора.

Кыскасроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме тәшкил итәчәк:
2023 ел: 3255646,43 сум, шул исәптән чаралар:
Татарстан Республикасы бюджеты – 323284,00 сум;
жирле бюджетлар – 304 000,00 сум;
күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре – 777838,20 сум.
2024 ел: 1329447,90 сум, шул исәптән чаралар:
Татарстан Республикасы бюджеты – 309692,14 сум;
жирле бюджетлар – 152 000,00 сум;

күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре – 867755,76 сум.
2025 ел: 1329447,9 сум, шул исәптән чаралар:
Татарстан Республикасы бюджеты – 309692,14 сум;
җирле бюджетлар – 152 000,00 сум;
күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре – 867755,76 сум.

2023 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сум |
|---|---|
| Фасадны җылыту | 2708400,35 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | 464296,00 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 67770,08 |
| Төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру | 15180,00 |

2024 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сум |
|---|---|
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | 201116,6 |
| Йорт эчендәге инж. салкын су бирү системаларын ремонтлау | 211276,50 |
| Йорт эчендәге инж. электр белән тәэмин итү системаларын ремонтлау | 412393,1 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 55544,60 |
| Төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру | 16848,20 |

2025 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сум |
|---|---|
| Йорт эчендәге инж. электр белән тәэмин итү системаларын ремонтлау | 260040,00 |
| Түбә ремонтлау | 455360,00 |
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | 215045,4 |
| Йорт эчендәге инж. салкын су бирү системаларын ремонтлау | 284380,00 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 86773,5 |
| Төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру | 27849 |

Муниципаль районның Башкарма комитеты күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау эшләрен уздыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан файдалануын тикшереп тора; тиешле муниципаль берәмлек буенча Кыскасроклы планны гамәлгә ашыру максатларында, Министрлык тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә белешмәләр базасын (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча белешмәләр) төзиләр һәм аларны

актуаль хәлдә тоталар; Министрлыкка һәм Кыскасроклы планны үтәүчеләргә фондка хисаплар формалаштыру өчен кирәкле белешмәләрне тапшыралар.

ТСЖ, идарәче оешмалар: милекчеләргә капиталь ремонтка кертемнәр буенча ай саен түләүләр кертәләр, капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә түләнә торган урыннар милекчеләреннән акчаларны җыюны гамәлгә ашыралар, Региональ оператор счетында капиталь ремонт фонды булдырылган очракта милекчеләрнең кертемнәрен региональ оператор счетына күчерәләр, һәр милекче буенча түләүләр һәм түләү турында мәгълүматны торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм аларның торышына дәүләт программасы үтәлешен мониторинглауның web-адресы буенча мөмкин булган мәгълүмати-аналитик системасына кертәләр: https//bars-monf.tatar/jif-mf/;

капиталь ремонтка кертемнәр буенча биналарның милекчеләренең бурычлары барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар күрелә; тикшерү актлары, капиталь ремонт буенча эш күләменә җитешсезлек исемлекләрен, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

региональ оператор белән түләү документларын формалаштыруга һәм капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләрнең ай саен исәпләнүен һәм түләүләрен региональ оператор счетына күчерүне тәэмин итүгә шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

торак милекчеләренә капиталь ремонт башлау вакыты, хезмәт күрсәтү һәм (яки) эш күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йорттагы гомуми милекне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тәкъдим итәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча милекчеләрнең җыелышларын оештыралар: капиталь ремонт объектларына керүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тоталар, шулай ук капиталь ремонттан соң күп фатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыруда катнашалар, аларның актларына кул кую хокукы ия була алалар;

дефект ведомостьлары, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча проект-смета һәм башкарма документацияне күпфатирлы йортны һәм аңа керүче инженерлык системаларын авариясез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия срогыннан да ким булмаган срокка саклыйлар.

Фатир хуҗалары

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә карата җитешсезлек исемлекләрен килештерәләр;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауны үз вакытында һәм сыйфатлы үтәүне контрольдә тотуда, шулай ук аларны тикшерү актларын һәм тәмамланган капиталь ремонт объектларын файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча Кыскасроклы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән вакыт эчендә эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплы; объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешма:

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар; башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны кулланышка кабул итүдә катнашалар, объектны кабул итү актын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау эшләрен сыйфатлы һәм үзвакытында башкарулары өчен җаваплы; проект оешмасыннан проект-смета документациясен кабул итәләр; күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куйганнан соң 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка тапшыралар, капиталь ремонт турында документларның күчермәләре (шул исәптән, проект, смета документларының, хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) капиталь ремонт эшләрен башкару турында килешүләрнең күчермәләре) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документлар, финанс документларыннан тыш, законнарда каралган техник заказчының башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

Җирле массакүләм мәгълүмат чаралары - «Теләче» газетасы (Теләче) массакүләм мәгълүмат чараларында кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру барышын даими яктыртып тора. Кыскасроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында тормышка ашырыла.

## VI. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкару өчен, подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар Регион операторы тарафыннан сайлап алына.

Эшләр белән идарә итүче И.Т. Һадиев